| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27 июня 2024г. с.Шалты № 101

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Шалты авыл җирлеге Советының 13.04.2018 № 50 карарына (16.05.2018 № 51, 15.10.2018 № 67, 19.11.2018 № 72, 04.09.2020 № 124, 17.12.2021 № 27, 22.09.2022 № 45 үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү турында

Баулы шәһәр прокуратурасының 15.01.2024 № 02-08-02/24 протестына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.09.2006 № 573 «Дәүләт серенә даими нигездә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча Структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» карарына «Вазыйфаи затларга айлык процент өстәмәләрен түләү кагыйдәләре белән бергә дәүләт серенә даими нигездә кертелгән гражданнарның һәм дәүләт серен саклау буенча Структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең хезмәт хакына (тариф ставкасына), муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, Җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарына үзгәрешләр кертү турында» 30.04.2024 № 290 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына нигезләнеп, Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Шалты авыл җирлеге Советының 13.04.2018 № 50 карарына (16.05.2018 № 51, 15.10.2018 № 67, 19.11.2018 № 72, 04.09.2020 № 124, 17.12.2021 № 27, 22.09.2022 № 45 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1-нче пунктның 3-нче абзацында «12 688» санын «13 323» санына алмаштырырга;

2-нче пунктның 3 пунктчасының 3-нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районның авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата бүләкләү өлешендә хезмәт хакына чыгымнар күләме елына 12,86 айлык акчалата бүләкләү нормативыннан артмаска тиеш.»;

6-нчы кушымтада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алмаштырырга.

13-нче кушымтаның 1-нче пунктында:

6-нчы пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алмаштырырга.

түбәндәге эчтәлектәге 7-нче пунктча белән тулыландырырга:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле фәнни дәрәҗә өчен вазифа хезмәт хакына айлык өстәмә вазифа хезмәт хакының 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.»;

күрсәтелгән карарның 2 һәм 15 нче кушымталарын яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин